**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня, улица
Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани
урамы, 6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24 декабрь 2025 ел. № 470

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының “Әтнә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында”гы 27.05.2019 № 161 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында нигезләмәне раслау хакында” Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 14.09.2022 № 135 (18.11.2022 №145, 27.01.2023 №165, 15.05.2024 №230, 16.11.2024 №246, 25.04.2025 №276, 12.12.2025 №15 үзгәрешләр белән) карарына таянып, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2025 елның 27нче октябрендәге 03-12/7278 номерлы хатын үтәүдә Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты **карар итә:**

1. “Әтнә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләре, баш бухгалтерлар һәм муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары бухгалтерлары хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында”гы 27.05.2019 ел, № 161 Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның 1 нче кушымтасының 3 нче пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының мәдәният һәм мәгариф бүлекләренең структур бүлекчәсе булган үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи хезмәт хаклары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазифалары | Вазифа хезмәт хакы, сум |
|---|---|
| | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органы) |

| | |
|---|---|
| | структур бүлекчәсе (бүлеге)булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | 38100 |
| Бүлек башлыгы | 33600 |
| Җитәкче бухгалтер | 30600 |
| Бухгалтер | 29000 |

Башкарма комитетның мәдәният һәм мәгариф бүлекләренең структур бүлекчәсе булган үзәкләштерелгән бухгалтерияләрнең штат расписаниесенә бүлек башлыгы вазыйфасын кертү шарты булып һәркайсында штат саны кимендә 5 берәмлек булган бүлек структурасында булу тора.

Башкарма комитетның мәдәният һәм мәгариф бүлекләренең структур бүлекчәсе булган үзәкләштерелгән бухгалтерияләр бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.”;

1.2. карарга 2 нче кушымтаның 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары бухгалтерларының вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 31000 рублей | 32700 рублей |
| Бухгалтер | - | 29700 рублей |

Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының штат расписаниесенә бухгалтер вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 меңнән артык кеше тора.”.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 нче гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.И. Гыймадиевка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов